МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.03.2023 Казан ш № 136

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме

күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.09.2018 №904, 03.06.2019 №422, 14.11.2019 №1019, 25.06.2020 №460, 08.10.2020 №713, 17.12.2020 №861, 02.12.2021 №897, 12.09.2022 №860 боерыклары нигезендә кертелә торган үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның «03» мартындагы 136 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә боерык бирәм:»

2 пунктта «, КФҮ ерактагы эш урыннары аша» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге боерык белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2 бүлектә:

2.2.2 пунктында «һәм (яки) КФҮнең ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3.2 пунктының икенче абзацында «(алга таба – Бердәм цифрлы платформа),» сүзләреннән соң «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru) (техник мөмкинлекләр булган очракта) (алга таба – Бердәм портал),» сүзләрен өстәргә;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

2.4.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән очракта, әлеге Регламентның 3.1 пунктының «и» - «л» пунктчаларында каралган

административ процедуралардан (гамәлләрдән) тыш, дәүләт хезмәте анық ихтыяры буенча мөрәҗәгать итү көнендә күрсәтелә.

2.4.2. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризалар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан гражданин анда эшсез сыйфатында исәптә тора торган халыкның мәшгульлек үзәгенә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, шәхси кабинет аша электрон документ формасында бирелгән булса, дәүләт хезмәте гаризаны һәм документларны теркәгән көннән башлап 47 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан җибәрелгән көнне халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан кабул ителгән дип санала.

2.4.3. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчедән халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу зарурлыгы булуы турында мәгълүмат алынган көннән соң икенче эш көненнән соңга калмыйча, һөнәргә укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыра һәм җибәрә.

2.4.4. Халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы белән әлеге Регламентның 3.11.3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән вакытка гражданин һөнәри белем алган яисә өстәмә һөнәри белем алган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла.

2.4.5. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхси кабинет аша Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Татарстан Республикасы порталы, КФҮ аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте әлеге Регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән срокларда гамәлгә ашырыла.»;

2.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында:»;

2.6.1 пунктта «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда),» сүзләрен өстәргә;

2.6.3 пунктта:

бишенче абзацта «якиерактагы эш урыны» сүзләрен алып ташларга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булган очракта).»;

2.6.4 пунктның өченче абзацында «, КФҮ ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.6. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәве турында (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан);

юридик затларны гамәлгә куючылар (катнашучылар) булган гражданнар турында (Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан);

һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусы турында (Федераль салым хезмәтеннән, «Һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусын тикшерү» гавами сервисы);

инвалидлык турында белешмәләр (инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан өземтә (мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта)(Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан («Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә түбәндәге белешмәләр алына:

мөрәҗәгать итүче паспортының гамәлдә булуын раслау турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлүенең гамәлдә булуын раслау турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан).

Гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.»;

2.6.7, 2.6.8 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

2.8.2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итүчедә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр финанс ярдәме бирү турында шартнамәләр (алга таба – шартнамә) төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көненә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән бурычларның булуы;»

2.8.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар Бердәм цифрлы платформада, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Татарстан Республикасы порталында теркәлә һәм халыкның мәшгульлек үзәге Бердәм цифрлы платформадан, Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерүне җибәрә.»;

2.10.1 пунктта «, КФҮ ерактагы эш урыны аша» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.13.1 пунктның бишенче абзацында «, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында;» сүзләрен «(техник мөмкинлек булганда), Татарстан Республикасы порталында;» сүзләренә алмаштырырга;

2.13.6 пунктта «, КФҮ ерактагы эш урыны аша» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.13.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Бердәм цифрлы платформада, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Татарстан Республикасы порталында, Министрлыкның рәсми сайтында, КФҮдә алырга мөмкин.»;

2.14.2 пунктында «Бердәм порталга һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталына» сүзләрен «Бердәм порталга (техник мөмкинлек булганда), Татарстан Республикасы порталына» сүзләренә алмаштырырга,»;

2.14.4 пунктында «Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында» сүзләрен «Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Татарстан Республикасы порталында» сүзләренә алмаштырырга,»;

3 бүлектә:

3.1 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«м) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны (алга таба – техник хата) төзәтү.»;

3.2.1 пунктның беренче һәм икенче абзацларында «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), « сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктта «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда),» сүзләрен өстәргә;

3.3.1 пунктта:

«Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.4.1^1$ пунктын өстәргә:

«$3.4.1^1$ Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Халыкның мәшгульлек үзәгендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, халыкның мәшгульлек үзәге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша документлар һәм мәгълүматлар сората.

Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәгенең ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган белгече әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен сорала торган документлар (белешмәләр) исемлеге:

шәхси эшкуар буларак дәүләт теркәве турында мәгълүматлар. Мәгълүмат бирү турындагы гариза Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына җибәрелә;

юридик затларны гамәлгә куючылар (катнашучылар) булган гражданнар турында белешмәләр. Мәгълүмат бирү турындагы гариза Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына җибәрелә;

һөнәри керемгә салым түләүченең (үзмәшгуль) статусы турында белешмәләр. Мәгълүмат бирү турында гариза Федераль салым хезмәтенә, «(Үзмәшгульнең) һөнәри керемнә салым түләүче статусын тикшерү» гавами сервисына җибәрелә;

гариплек турында белешмәләр (гариплеге булган затның хосусый терһәкләндерү яисә абилитацияләү программасыннан өземтә (мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта); Мәгълүмат бирү турында гариза Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына («Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына) җибәрелә;

мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә түбәндәге белешмәләрне бирү турында:

мөрәҗәгать итүченең паспорты гамәлдә булуын раслау турында. Белешмәләр бирү турында гариза Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүченең теркәлүенең гамәлдә булуын раслау турында. Белешмәләр бирү турында гариза Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә  дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә  ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән гарызнамәләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.»;

3.4.2 пунктның беренче абзацында «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда),» сүзләрен өстәргә;

3.8.2 пунктта «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда),» сүзләрен өстәргә;

3.8.3 пунктның дүртенче абзацында «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда),» сүзләрен өстәргә;

3.10.2 пунктта «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда),» сүзләрен өстәргә;

3.10.3 пунктның беренче абзацында «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда),» сүзләрен өстәргә;

3.10.6 пунктта «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда),» сүзләрен өстәргә;

3.12.5 пунктта «Бердәм цифрлы платформа» сүзләреннән соң «Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда),» сүзләрен өстәргә;

3.13 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хатаны төзәтү.»;

3.13.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.13.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы документларны яңадан рәсмиләштерә;

- мөрәҗәгать итүчегә аның гаризасында күрсәтелгән ысул белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында документларны яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү турында яңадан рәсмиләштерелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында яңадан рәсмиләштерелгән документлар турында хәбәр итү.»;

3.13.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

4 бүлектә:

4.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

5 бүлектә:

5.2 пунктның икенче абзацында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)» сүзләрен «210-ФЗ номерлы федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затлар тарафыннан шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatarstan.ru), Бердәм портал (https://www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасы порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта буенча, «Интернет» челтәре, КФҮ рәсми сайты (http://mfc16.tatarstan.ru), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасы порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.»;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.